Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясындагы $3^1$ пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7; Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) беренче абзацта «билгеләнә» сүзен «раслана» сүзенә алмаштырырга;

2) 6 пунктчада «һәм чыгымнар төрләре» сүзләрен «һәм чыгымнар төрләре төркемнәре» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сәламәтлек саклау өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 мартындагы 19-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:

а) 3 өлештә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

2) 1 нче кушымтада:

а) исемдә «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «субвенцияләрнең күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта татарча текст үзгәрми;

дүртенче абзацта татарча текст үзгәрми;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$S_{ti1}$ – эпидемиягә каршы чаралар үткәрүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган бәясе.»;

3) 2 нче кушымтада:

а) исемдә «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта татарча текст үзгәрми;

дүртенче абзацта татарча текст үзгәрми.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына архив эше өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында» 2007 елның 24 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2013, 19 октябрь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 пунктында «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

2) кушымтада:

а) исемдә «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта «субвенцияләр күләмен билгеләү өчен нормативларны» сүзләрен «субвенцияләрне» сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктта:

беренче абзацта татарча текст үзгәрми;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Р – саклау бирәмлеген карап тотуга чыгымнарның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нормативы;».

**4 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60[1] статьясы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә), 2014 елга, 2015 һәм 2016 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 89-ТРЗ